РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 33 2022 елның 1 июне

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 декабрендә кабул ителгән 43 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында Нигезләмәне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 декабрендә кабул ителгән 43 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында Нигезләмәне раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1.2 Түбән Кама муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте, мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм чыгымнары турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте, мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм чыгымнары турында мәгълүматлар (алга таба – керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар).»;

10 пунктта «Түбән Кама муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия тарафыннан» сүзләрен «Түбән Кама муниципаль районының хезмәт (вазыйфа) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның «в» пунктчасында, 13 пунктта «, акцияләрне» сүзен төшереп калдырырга;

Карарга 3 нче кушымта сыйфатында кушымта итеп бирелә торган Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.В.Умников

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2022 елның 1 июнендә кабул ителгән 33 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 декабрендә кабул ителгән 43 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында Нигезләмәне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карарына
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы
Советының 2014 елның 18
декабрендә кабул ителгән 43
номерлы карарына
3 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында
нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә Түбән Кама муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең муниципаль хезмәткәрләренә, мондый җирлекләр тарафыннан Түбән Кама муниципаль районына «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт өлкәсендә муниципаль хокукый актлар кабул итү вәкаләтләрен тапшырган очракта, үз көчен җәелдерә.

2. Әлеге Нигезләмә белән түбәндәгеләрне тапшыру тәртибе билгеләнә:

Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, аларга милек хокукында караган мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының аларга милек хокукында караган мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар (алга таба – керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар);

Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат (алга таба – керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар);

3. Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданның (алга таба – граждан) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү бурычы, шулай ук Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлеге җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәренең (алга таба – муниципаль хезмәткәр) кереме, чыгымы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү бурычы аларга йөкләнә, әгәр аны биләүгә граждан дәгъва итә торган яки муниципаль хезмәткәр били торган Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлеге җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган тәртиптә муниципаль хезмәт вазыйфаларының тиешле исемлегенә (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) кертелгән булса.

4. Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар гражданнар тарафыннан Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча, Вазыйфалар исемлегендә каралган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә тапшырыла.

5. Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча Вазыйфалар исемлегендә каралган муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

6. Граждан муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә түбәндәгеләрне тапшыра:

а) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә документлар тапшыру елыннан алдагы календарь ел өчен барлык чыганаклардан (элекке эш урыны яки сайланулы вазыйфа биләү урыны буенча керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәр турында белешмәләр, шулай ук граждан тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә документлар бирү елына кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) милек хокукында булган мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә документлар тапшыру елыннан алдагы календарь ел өчен барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында белешмәләр, шулай ук граждан тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә документлар бирү елына кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) милек хокукында булган мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

7. Муниципаль хезмәткәр ел саен тапшыра:

а) барлык чыганаклардан (акчалата түләү, пенсияләр, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры азагына милек хокукында булган мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) алынган керемнәр турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында булган мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

в) мәгълүмат тапшыру елы алдыннан килгән календарь елы эчендә (алга таба – хисап чоры) аның, хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары тарафыннан башкарылган җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталында катнашу өлеше, пайлары), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алуга һәр алыш-биреш буенча үзенең чыгымнары, хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр

мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге өч соңгы ел эчендә әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми керемennән артып китсә, һәм әлеге алыш-бирешләр башкарылган акчалар алу чыганаклары турында белешмәләр.

8. Вазыйфалар исемлегенә кертелмәгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче һәм Вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы муниципаль хезмәткәр әлеге Нигезләмәнең 3, 4 һәм 6 пунктлары нигезендә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра.

9. Әлеге Нигезләмәнең 6 һәм 7 пунктларында каралган белешмәләр җирле үзидарә органының (муниципаль орган) кадрлар хезмәтенә (кадрлар хезмәте буенча белгечкә) җирле үзидарә органы җитәкчесе (муниципаль орган) исеменә тапшырыла.

10. Әгәр граждан яисә муниципаль хезмәткәр алар тарафыннан җирле үзидарә органының (муниципаль органның) кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгеченә) тапшырылган мәгълүматларда нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмаган яисә тулысынча чагылдырылмаган яки хаталар булуын ачыклаган очракта, алар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә анықланган белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

Муниципаль хезмәткәр әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә анықланган белешмәләрне тапшыра ала.

11. Объектив сәбәпләр аркасында, муниципаль хезмәткәр тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмаган очракта, бу факт хезмәт (вазыйфа) урынында үз-үзен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссиядә каралырга тиеш.

12. Әлеге Нигезләмә нигезендә граждан һәм муниципаль хезмәткәр тапшырган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

13. Граждан һәм муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырыла торган белешмәләр, әгәр федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр булып санала.

Бу белешмәләр муниципаль хезмәткәрләрне вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү вәкаләтләре бирелгән җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесенә һәм җирле үзидарә органының башка вазыйфаи затларына, шулай ук федераль законнарда каралган очракларда башка вазыйфаи затларга тапшырыла.

14. Әлеге Нигезләмә нигезендә граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләр белән эшләү вазыйфаи бурычларына керә торган муниципаль хезмәткәрләр аларны таратуда яки Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда файдалануда гаепле булсалар, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

15. Муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән граждан яисә муниципаль хезмәткәрнең әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр ел саен тапшыра торган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр һәм әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә теркәлә. Әлеге мәгълүматлар шулай ук электрон рәвештә саклана ала.

Җирле үзидарә органына (муниципаль органга) үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырган Әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән граждан яисә муниципаль хезмәткәр Вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнмәгән булса, бу белешмәләр аларга язма гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла.

16. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм

мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырмау, әгәр мондый белешмәләр тапшыру мәҗбүри булса, яисә белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары А.В.Умников